Педагогик киңәшмә тарафыннан
**кабул ителде**
беркетмә №
«    »              20      ел
педагогик киңәшмә рәисе
_____________Исхаков Ф.Ф.

**Расланды**
Нурлат шәһәре “1нче урта гомуми белем мәктәбе” МАГББУ директоры
_________Исхаков Ф.Ф.
Боерык №
«    »              20     ел.

**Татарстан Республикасы Нурлат шәһәренең “1нче урта гомуми белем мәктәбе” муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесендә башлангыч гомуми белем бирүнең төп белем бирү программаларын үзләштерү нәтиҗәләрен бәяләү Нигезләмәсе.**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

- Нигезләмә түбәндәге документларга таянып эшләнелде:
- “Россия Федерациясендәге мәгариф турында” 29.12.2012нче елгы 273нче номерлы-ФЗ Федераль канун,
- Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 6.10.2009 нчы елгы 373нче номерлы боерыгы белән расланган Башлангыч гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандартлары,
- Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Башлангыч гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандартларына үзгәрешләр кертү турында” 26.11.2010нчы елгы 1241нче номерлы боерыгы,
- Татарстан Республикасы Нурлат шәһәренең “1нче урта гомуми белем мәктәбе” муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе уставы (ары –Нурлат шәһәре «“1нче урта гомуми белем мәктәбе”» МАГББУ).

1.2 Әлеге Нигезләмә:

- укучыларның шәхси, предмет, метапредмет нәтиҗәләрен, универсаль уку гамәлләрен бәяләүне оештыру нигезләрен, арадаш аттестация тәртибен һәм формаларын, башлангыч гомуми белем дәрәҗәсенең Башлангыч гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү таләпләренә туры килү-килмәвен билгели һәм үтәү өчен мәҗбүри булып тора;
- белем бирү учреждениесенең Башлангыч гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандартларын тормышка ашыру шартларында бәяләүне оештыру үзенчәлекләрен һәм принципларын, арадаш аттестация тәртибен һәм формаларын аңлату максатыннан эшләнелгән локаль акты булып тора;

- үзенең үзгәртүләрен һәм өстәмәләрен кертергә хокукы булган мәктәпнең педагогик киңәшмәсе тарафыннан раслана;
- укучыларның укудагы уңышларын бәяләүгә, шулай ук агымдагы һәм арадаш контрольнең тәртибе, формасы, кабатлануына карата таләпләр билгели.

**2. Контроль-бәяләү эшчәнлеге принциплары**

3. Контроль-бәяләү эшчәнлегенең төп принциплары булып:

- Критерийлык: планлаштырылган нәтиҗәләргә контроль һәм бәяләү стандарт таләпләрендә каралган критерийлар нигезендә төзелә. Критерийлар булып курс, бүлек, тема, дәрес, универсаль уку гамәлләре буенча максатчан багланыш тора.
- Белем бирү нәтиҗәләренең Башлангыч гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандартларына туры килгән база һәм югары дәрәҗәгә ирешүгә нигезләнгән контроль чараларын эшләүне күздә тоткан контроль һәм бәяләүнең баскычлы характерда булуы .
- Бәяләүнең комплексслы булуы – нәтиҗәләрне кушу мөмкинлеге .
- Укучы үзбәяләвенең укытучы бәяләвеннән алдан булуы ( үтәләсе эшкә үзбәяләүне прогнозлау һәм эшләнелгән эшне бәяләү).
- Нәтиҗәләрне бәяләүнең төрле формада һәм сыгылмалы булуы: эчтәлекле контроль һәм бәяләү укыту нәтиҗәлелеген өйрәнү методларын һәм төрле процедуралар куллануны күздә тота, бәяләү инструментларының вариативлыгы һәм аларны тормышка ашыру чараларының күптөрле булуы, уку эшчәнлегенең индивидуаль, шулай ук төркем, коллектив нәтиҗәләрен өйрәнү.
- Ачык булуы: бәяләүнең максаты, эчтәлеге, форма һәм методлары турында бәяләү мәгълүматы укучылар һәм ата-аналарга җиткерелергә тиеш. Укучының уку һәм үсеше буенча индивидуаль нәтиҗәләр турындагы мәгълүмат адреслы булырга тиеш .

4. Контроль һәм бәяләү процессының табигыйлыгы: Контроль һәм бәяләү укучылар өчен киеренкелекне һәм стрессны киметүгә нигезләнгән табигый шартларда үткәрелергә тиеш. Мәктәп укучыларының уку-танып белү эшчәнлеге сыйфатнамәсенә аларның табигый шартларда уку эшенә күзәтү нәтиҗәләре кертелә.

**5. Укучыларның планлаштырылган нәтиҗәләренә контроль**

3.1 Контроль объекты булып предмет, метапредмет нәтиҗәләре тора.

3.2 Контроль критерийлары булып планлаштырылган нәтиҗәләргә стандарт таләпләре, курс, бүлек, тема, дәрес буенча максатчан багланыш тора.

3.3 **Контрольның төп төрләре:**

- Башлангыч (старт) контроль. Уку елы башында (яки яңа зур бүлекләрне өйрәнү алдыннан) үткәрелә. Диагностик характерда була. Башлангыч (старт) контрольның максаты: Укучының үткәреләсе эшчәнлеккә бәйле булган белем, күнекмә һәм универсаль уку гамәләренең әзерлек дәрәҗәсен билгеләү.
- Тематик контроль (дәрес, темалар, бүлек, курс); укыту гамәле тәмамланганнан соң фактик нәтиҗәләрне яки үткәрелгән эшләрне үрнәк белән чагыштыру методы аша уздырыла.
- Йомгаклау контроле уку елы азагында белем бирү нәтиҗәләрен ( шулай ук метапредмет) комплексы тикшерүне күздә тота.
- Шәхси белем казанышлары динамикасы контроле (портфолио тупланма бәяләү системасы).

3.4 **Контроль формалары һәм казанышларны теркәү**:

- диагностик эшләр;
- стандартлаштырылган язма һәм телдән эшләр;
- комплекслы диагностик һәм контроль эшләр;
- тематик тикшерү(контроль) эшләре;
- үзанализ һәм үзбәя;
- укучыларның индивидуаль тупланма портфолиосы;

3.5 **Контрольгә таләпләр** :

- контроль барлык укучылар мәнфәгатьләрендә һәм аларны укыту, тәрбияләү һәм үсеш максатыннан кулланыла;
- контрольнең аерым укучы өчен дә, тулы класс өчен дә регулярлыгы һәм системалылыгы;
- контрольнең белем бирү стандартларын үзләштерүдә дә, универсаль күнекмәләр формалаштыруда да чагылыш тапкан күпьяклылыгы;
- контрольнең теләсә нинди формаларында барлык укучылар өчен тигез шартлар булдыруны сораган объективлыгы;
- нәтиҗәләре турында кыска вакыт эчендә тиешле мәгълүмат алып була торган итеп оештырылган оптималь контроль;
- контроль мотивлаштыручы һәм диагностик булырга тиеш.

3.6 Тематик һәм йомгаклау эшләренең саны һәр предмет буенча эш программаларына туры китереп урнаштырылган.

## 6. Бәяләү нәтиҗәләре

- Йомгаклау билгесе предметы булып, укучыларның уку предметы эчтәлегенә релевант, шул исәптән метапредмет гамәлләр нигезендәге чаралар кулланып, белемнәрнең таяну системасы материалында төзелгән уку-танып-белү һәм уку-практик мәсьәләләрне чишү сәләте тора.
- Башлангыч гомуми белем бирү баскычында персонифиц. йомгаклау билгесенә гомуми белем бирүнең киләсе баскычында укуны дәвам итү мөмкинлеге яки мөмкин булмавы турында карар кабул иткәндә кулланыла торган нәтиҗәләр, бары тик предмет һәм метапредмет нәтиҗәләр чыгарыла.
- Башлангыч гомуми белем бирү баскычында укучыларның Стандарт таләпләренә тулысынча туры килгән шәхси нәтиҗәләре йомгаклау билгесенә алынмый. Алар төрле мониторинг тикшеренүләре предметы булып тора.
- **4.1** Бәяләүнең төп функцияләре булып**:**
- мотивлаштыру – укучыны белем алу эшчәнлегенә кызыксындыра һәм аны дәвам итүне стимуллаштыра;
- диагностик – укучының теге яки бу белем нәтиҗәләре сәбәпләрен күрсәтә, уку казанышларының индивидуаль динамикасын ачыклый;
- тәрбияви – мәктәп укучысының уку эшчәнлегенә карата үзаң һәм адекват үзбәясен формалаштыра;
- мәгълүмати – укучының белем, күнекмә һәм эшчәнлек алымнары, сәләтләре үсеше, Башлангыч гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандартларына туры килгән предмет, метапредмет нәтиҗәләренә ирешүдә уңышлылык дәрәҗәсе турында сөйли.

### 4.2 Бәяләүнең форма һәм методлары

Башлангыч гомуми белем бирү баскычында күбесенчә бәяләүнең төрле формалары һәм методларын үз эченә алган эчке бәяләүне куллану киңәш ителә:

- укучыларның индивидуаль, шулай ук парларда, төркемнәрдә ( уку һәм сөйләү, сөйләшүдә катнашу, проектлар һәм кечкенә тикшеренүләр үткәрү һ.б) эшләнелә торган төрле иҗади биремнәр үтәү процессын бәяләү;
- телдән дә, язма да бирелгән ачык җавапларны бәяләү ( ягъни укучы тарафыннан ирекле форматта бирелгән);
- бирем форматы буенча чикләнгән ябык яки өлешчә ябык җавапларны (җавабы сайлаулы биремнәр, ирекле кыска җаваплы биремнәр) бәяләү;

- укучыларның рефлексия нәтиҗәләрен бәяләү (төрле үзанализ битләре, казаныш битләре, укучыларның көндәлеге һ.б.);
- укучыларның укудагы аерым эшчәнлек аспектларын яки аларның хәрәкәтен күзәтү (мәсәлән, уку һәм язу техникасының камилләшүен, яки коммуникатив һәм тикшеренү күнекмәләренең үсүен күзәтү).

### 4.3 Бәяләү механизмы

- Беренче уку елында башлангыч мәктәп укучыларын бәяләү критерийлар нигезендә телдән сыйфатлы билге формасында алып барыла.
- 2нче сыйныфтан башлап агымдагы бәяләүгә «5», «4», «3», «2» ( бәяләү шкаласына туры килгән) билгеләре куела. Журналга тематик тикшерү (контроль) эшләр, чирек нәтиҗәләре буенча стандартлашкан контроль эшләр, проектлар, иҗади биремнәр, практик эшләр, телдән тулы җаваплар, шигырьләрне сәнгатьле уку һәм ятлау, эчтәлек сөйләү һ.б. өчен билге куела.
- Белем, күнекмә һәм универсаль уку гамәлләре турында сыйфатлы характеристика укучының «портфолио»сы, аның рефлексив үзбәяләве нигезендә төзелә.
- Контроль һәм бәяләү нәтиҗәләрен билгеләү чаралары: класс журналлары, электрон журналлар, портфолио.

### 4.4 Агымдагы бәяләү

- Билгесез укытуда (1нче сыйныф) бәяләү шкала, диаграмма, баскыч ярдәмендә билгеләнелә.
- 2нче сыйныфтан башлап бәяләү уңышлылык дәрәҗәсе билгеләре буенча, шулай ук 5баллы шкала кулланып алып барыла.

Укучыларның индивидуаль казанышларын бәяләү өчен төп күрсәткеч сыйфатында уку программасын үзләштерү уңышлылыгы (башкарылган эшләр өчен алырга мөмкин булган максималь балл %), база дәрәҗәсенә ирешү һәм укучыларның казаныш дәрәҗәләре кулланыла.

Укучыларның предмет буенча казанышлары дәрәҗәсен 5 төркемгә бүләргә мөмкин (тиешенчә түгел, түбән, база, күтәренке, югары)

**тиешенчә түгел -** базага караган белем һәм күнекмәләрнең күп өлешен үзләштермәүче укучылар;

**түбән казанышлар -** әзерлекнең база дәрәҗәсенә җитә алмаучы, бары тик базага караган белем һәм күнекмәләрнең аерым өлешен генә үзләштергән укучылар;

**әзерлекнең база дәрәҗәсе** – әзерлекнең база дәрәҗәсенә җитә алган, ләкин катлаулы биремнәрне үтәгәндә сәләтләрен күрсәтә алмаган, ягъни алар

таныш булмаган яңа ситуациядә кыенлык кичерүче укучылар. Аларда базага караган белем күнекмәләре һәм уку гамәлләрен стандарт ситуацияләрдә куллану тәҗрибәсе генә формалашкан.;

**күтәренке дәрәҗә** – әзерлекнең база дәрәҗәсенә җитә алган һәм тупланган белемнәрен үзгәртелгән яки яңа ситуацияләрдә куллану сәләтен күрсәтә белгән укучылар;

**казанышларның югары дәрәҗәсе** - нык база әзерлеге һәм тупланган белемнәрне үзгәртелгән яки яңа ситуацияләрдә ышанып куллану сәләтен күрсәтә белгән аеруча әзерлекле һәм сәләтле укучылар.

Югарыда күрсәтелгән йомгаклау эшләрен үтәүне дифференциаль бәяләү укучыларны әзерлек дәрәҗәсе буенча төрле төркемнәргә бүлергә, һәм укытучыга, төркемнең үзенчәлекләрен исәпкә алып, төп мәктәптә укытуны оештыруда индивидуаль якын килергә мөмкинлек бирә.

2-4нче сыйныфларда укучыларның уку программаларын үзләштерү уңышлылыгы «5», «4», «3», «2» билгеләре формасында бәяләнә. Шәхси кәгазьләрендә һәм сыйныф журналында 5баллы шкала буенча билгеләр куела. 5баллы шкалага күчү билгеләнгән схема буенча алып барыла.

| Программаны үзләштерү сыйфаты | Казанышлар дәрәҗәсе | 5 баллы шкалада билге |
|---|---|---|
| 90-100% | югары | «5» |
| 66 -89% | күтәренке | «4» |
| 50 -65 % | база | «3» |
| 50% азрак | Тиешенчә түгел, түбән | «2» |

**4.5 Йомгаклау бәяләве**

Укучыларның башлангыч гомуми белем бирүдә төп белем бирү программаларын үзләштерүне йомгаклау бәяләве предметы булып белем алуны дәвам итү өчен кирәкле предмет һәм метапредмет нәтиҗәләренә ирешү тора.

Йомгаклау бәяләвендә ике туплаучы билгеләнергә тиеш:

укучыларның индивидуаль белем алу казанышлары динамикасын күрсәтүче, башлангыч гомуми белем бирүдә төп белем бирү программаларын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре казанышлары хәрәкәтен чагылдырган **арадаш аттестация нәтиҗәләре**;

гомуми белем бирүнең киләсе баскычында уку өчен кирәк булган белемнәр системасына кагылышлы төп эш-гамәл алымнарны үзләштерү дәрәҗәсен билгели торган **йомгаклау эшләре нәтиҗәләре.**

Башлангыч гомуми белем бирүдә төп белем бирү программаларын үзләштерүнең йомгаклау бәяләве белем бирү учреждениесе тарафыннан үткәрелә һәм укучыларның башлангыч гомуми белем бирүдә төп белем бирү программаларын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре кзанышларын бәяләүгә юнәлтелгән.

Башлангыч гомуми белем бирүдә төп белем бирү программаларын үзләштерүнең йомгаклау бәяләве нәтиҗәсе укучыларны гомуми белем бирүнең киләсе баскычына күчерү турында карар кабул иткәндә кулланыла.

Математика, рус теле, татар теле, әйләнә-тирә дөнья, белем алу күнекмәләре, мәгълүмати текстларны грамоталы уку өлкәләрендә белем нәтиҗәләре бәяләнә.

Башлангыч мәктәп укучыларының предмет буенча белем казанышларын бәяләү өчен предмет буенча йомгаклау эшләре үткәрелә.

Метапредмет белем нәтиҗәләрен (мәгълүмати текстларны грамоталы уку ) бәяләү өчен предметара нигездә комплекслы эшләр куллану киңәш ителә.

Язма эшләр сыйфатында предмет буенча йомгаклау эшләре һәм башлангыч мәктәп курсы буенча комплекслы эшләр кулланыла.

Белем алу күнекмәләре һәм уку хезмәттәшлеге кебек метапредмет белем нәтиҗәләрен бәяләү өчен күзәтү нигезендә әлеге күнекмәләрнең формалашу дәрәҗәсен ачыклау максатыннан төркемнәрдә проект эшләү киңәш ителә.

**Башлангыч мәктәп укучыларының белем казанышларын анализлау һәм интерпретацияләү**

Предмет нәтиҗәләрен бәяләү биш баллы шкала буенча билгеләнелә, метапредмет нәтиҗәләре дәрәҗә белән (I - VI) бәяләнә.

Башлангыч мәктәп курсы буенча бер сыйфат билгесе куела: “башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программаларын үзләштерә алмады”, яки “башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программаларын база дәрәҗәсендә үзләштерде”, яки “башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программаларын югары дәрәҗәдә үзләштерде”. Бу билге башлангыч мәктәп укучыларының предмет һәм метапредмет казанышларын, аларның 4нче сыйныфны тәмамлаган вакытка эшләнелгән эшләр билгесен һәм башлангыч мәктәптә уку барышында тупланган портфолио билгесен үз эченә алырга тиеш.

**Башлангыч мәктәп курсы буенча комплекслы йомгаклау билгесен кую тәртибе**

| Үзләштерү дәрәҗәсе | Йомгаклау билгесе | | Тупланма билге |
|---|---|---|---|
| | Предмет нәтиҗәләре | Метапредмет нәтиҗәләре | Портфолио |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Укучы башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программаларын база дәрәҗәсендә үзләштерде | Предмет буенча йомгаклау эшләре биремнәренең база дәрәҗәсе дөрес үтәлеше 50%тан ким булмаса | Предметара нигездәге комплекслы эшләр биремнәренең база дәрәҗәсе үтәлеше 50%тан ким булмаса | Уку программаларының барлык бүлекләре буенча планлаштырылган нәтиҗәләр казанышы портфолиода “зачет” яки ”канәгатьләнерлек” дип билгеләнгән булса |
| Укучы башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программаларын югары дәрәҗәсендә үзләштерде | Предмет буенча йомгаклау эшләре биремнәренең база дәрәҗәсе дөрес үтәлеше 50%тан ким булмаса һәм югары дәрәҗә биремнәр үтәлеше 65%тан ким булмаса | Предметара нигездәге комплекслы эшләр биремнәренең база дәрәҗәсе үтәлеше 50%тан ким түгел һәм югары дәрәҗә биремнәр үтәлеше 65%тан ким булмаса | Уку программаларының барлык бүлекләре буенча планлаштырылган нәтиҗәләр казанышы портфолиода бүлекләрнең яртысы өчен “яхшы” яки ”бик яхшы” дип билгеләнгән булса |
| Укучы башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программаларын үзләштерә алмады | База дәрәҗәсе биремнәренең дөрес үтәлеше 50%тан ким булса | Предметара нигездәге комплекслы эшләр биремнәренең база дәрәҗәсе үтәлеше 50%тан ким булса | Уку программаларының барлык бүлекләре буенча планлаштырылган нәтиҗәләр казанышы портфолиода билгеләнмәгән |

Әгәр дә үткәрелгән йомгаклау эшләре нәтиҗәләре буенча планлаштырган нәтиҗәләрне үзләштерү турында төгәл нәтиҗә ясап булмаса, укучыны укытуның киләсе баскына күчерү турындагы карар педагогик киңәшмә тарафыннан укучы портфолиосында күрсәтелгән белем

казанышлары динамикасын, шулай ук әлеге укучының уку үзенчәлекләре һәм шартлары турындагы мәгълүматны исәпкә алып кабул ителә.

## 7. Укуны бәяләү нәтиҗәләренең яңа системасы процессында ата-аналар белән үзараэш

5.1.Укытучылар ата-аналар җыелышларында ата-аналарны (аларны алыштыручы затларны) бәяләү критерийлары һәм үзенчәлекләре белән таныштырырга, уку эшчәнлеген бәяләүнең әлеге системасы өстенлеген исбатларга һәм аларның хуплавына һәм ярдәменә таянырга тиеш.

5.2. Укытучылар укучыларның ата-аналарына мәгълүмат җиткерү максатыннан аларның балалары үсеше һәм уку нәтиҗәләре турында даими индивидуаль консультацияләр үткәрәләр, укучыларның көндәлекләрендә агымдагы казанышларын билгелиләр, ә чирек нәтиҗәләре буенча үткәрелгән ата-аналар җыелышларында уку эшчәнлеге нәтиҗәләре белән таныштыралар һәм үзләренең рекомендацияләрен бирәләр.

5.3. Контроль-бәяләү эшчәнлеге кысаларында укытучылар, укучылар, ата-аналар һәм мәктәп администрациясе арасында тигезхокуклы хезмәттәшлек оештыру мөһим. Мондый хезмәттәшлектәге һәр катнашучы үз эшчәнлегенә үзбәя, башкалар эшчәнлеген бер субъект бәяләвенә карата үз дәлилләнгән фикере булуына хокуклы.

## 8. Мәктәп администрациясе

6.1. Мәктәп администрациясе үз эшчәнлегендә мәктәптә үстерелешле укытуның эффективлыгы һәм тормышка ашыруның тулаем картинасын булдыру өчен укытучылар, укучылар һәм психологның кирәкле булган барлык материалларын куллана.

6.2. Ел ахырында мәктәп директоры урынбасары укытучылардан алынган материаллар нигезендә педагогик коллектив эшенә педагогик анализ ясый, укучыларның да, укытучыларның да казанышлары һәм авырлыклары, “проблемалы” урыннарын күрсәтә һәм шулар нигезендә киләсе уку елына стратегик бурычлар билгели.